СОВЕТ ШАДЧИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Молодежная, д.18, с. Шадчи,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422145

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ШӘДЧЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Яшьләр ур., 18 нче йорт, Шәдче авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422145

тел.(факс): (85563) 2-52-24; e-mail: Shad.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Карар Решение

№ 3-24 13 июнь 2023 ел

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Шәдче авыл җирлеге Советының 2015 елның 30 апрелендәге 6-43 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

“Дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалануны тәэмин итү турында” 2009 елның 9 февралендәге 8-ФЗ номерлы, "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 ноябрендәге 131-ФЗ номерлы, “Дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалануны тәэмин итү турында” Федераль законга һәм “Россия Федерациясендә судлар эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалануны тәэмин итү турында” Федераль законның 10 статьясына үзгәрешләр кертү хакында"2022 елның 14 июлендәге 270-ФЗ номерлы федераль законнар, “Татарстан Республикасы дәүләт органнары һәм Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалануны тәэмин итү хакында" 2015 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы, Мамадыш муниципаль районы Шәдче авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Мамадыш муниципаль районы Шәдче авыл җирлеге Советы **карар кабул итте:**

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Шәдче авыл җирлеге Советының 2015 елның 30 апрелендәге “Мамадыш муниципаль районы Шәдче авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында интернет челтәрендә урнаштырыла торган мәгълүмат исемлеген раслау турында" 6-43 номерлы карарына (алга таба – Карар) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Исемендә, 1 пунктта һәм 1 нче кушымтада "Интернет челтәрендә” сүзләрен " рәсми сайтларда" сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында, Мамадыш муниципаль районының mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматларының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Мамадыш муниципаль районы Шәдче авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Башлык,Мамадыш муниципаль районы
Шәдче авыл җирлеге
Советы рәисе /В.В.Шрыков